**Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 13-2 «22» октябрь 2020 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2018 елның 30 мартындагы 87-24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә хакында» карары белән расланган, "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (2019 елның 20 августындагы 143-35 номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 155-38 номерлы карарлар редакциясендә)

2009 елның 02 августындагы 301-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге 293-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федераль закон нигезендә

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Советының 2018 елның 30 мартындагы 87-24 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлеге муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмә хакында» карары белән расланган, "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай шәһәре» муниципаль берәмлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе турында» нигезләмәгә (2019 елның 20 августындагы 143-35 номерлы, 2019 елның 12 декабрендәге 155-38 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7.3 пунктның 3 абзацында. «хезмәт өчен түләүнең федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән илле мең тапкырдан артыграк» сүзләрен «федераль закон белән билгеләнгән минималь күләменнән дәүләт унитар предприятиесе устав фонды минималь күләменнән 10 тапкырдан артык" сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 9.1 пунктта " федераль мөлкәтне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы), Россия Федерациясе субъектлары милкендә булган муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру актлары" сүзләрен "дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыруның фараз планы (программасы)" сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 9.5 пунктта «хосусыйлаштыру» сүзләреннән соң «дәүләт һәм» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга:http://aznakayevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин